**Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение**

**«Усть-Туркская средняя общеобразовательная школа»**

**Бажуковский филиал**

| | |
|---|---|
| СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| Заместитель директора | Директор |
| ____________/Аитова Э.Р. | ____________/Юсупова И.Ф. |
| | Приказ №271-07-01-11-111 |
| | от 01.09.2025 г. |

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**

**курса внеурочной деятельности**

**«Морфология татарского языка»**

для обучающихся 6го класса

**с. Бажуки, 2025г.**

## Аңлатма язуы

«Татар теленең морфологиясе " программасы укучыларның дөньяга карашын һәм фикерләвен үстерә, аларның үсешенә ярдәм итә, татар теленә хөрмәт хисе тәрбияли. Дәресләрдә укучылар әлеге тема буенча тирәнтен белем алалар. Курс программасында мавыктыргыч морфология элементлары, уен дәресләре бар, сөйләм культурасы буенча материал, шулай ук сөйләм иҗаты дәресләре бар. Алар сөйләм күнекмәләрен үстерергә, танып белү эшчәнлеген активлаштырырга ярдәм итә.

Хәзерге мәктәпнең төп бурычы - белем бирү генә түгел, ә укучыда шәхес булдыру, укуга кызыксыну уяту, үз-үзеңне камилләштерергә омтылыш тәрбияләү. Дәрестән соң “ Татар теленең морфологиясе” түгәрәгендә балаларда татар теленә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләп була .

Кызганыч, түгәрәкләр үткәрү өчен махсус төзелгән программалар юк, методик кулланмалар да юк. “ Татар теле морфологиясе ”түгәрәгенә 1 сәгать вакыт бирелгән. Шул вакыт аралыгында авыр үзләштерелә торган темаларны кызыклы формаларда, уеннар аша бирүне күздә тотам. Халык авыз иҗаты әсәрләре, Р.Фәхретдин, К.Насыйри хезмәтләренә нигезләнеп, шулай ук төрле язучы-шагыйрьләрнең иҗатларыннан үрнәкләрне материал итеп кулланып, сюжетлы рәсемнәрдән, грамматик биремле карточкалардан файдаланып эшләүне уңышлы саныйм. Видео материаллар, магнитофон язмаларын, мультфильмнарны актив куллануны да кирәктер дип уйлыйм.

Дәрестән соң, түгәрәкләр кызыклы итеп үткәрелә икән, балалар өйгә бирелгән эшләрен тизрәк һәм теләп башкаралар, уку хезмәте алар өчен җиңелрәк була һәм мәктәпкә балалар ашкынып, яратып йөриләр.

Программада 34 сәгать вакыт каралган (атнага бер сәгать исәбеннән). Һәрбер эш юнәлешенә темалар күрсәтелә, сәгатьләр саны бирелә. Программада милли-региональ компонентларга һәм татар халык авыз иҗатын өйрәнүгә зур урын бирелә. Чөнки әдәп-әхлак нормалары югалып барган хәзерге чорда, тәрбия өлкәсендә халык педагогикасына, аның гасырлар буе тупланган тәҗрибәсенә таянып эшләгәндә генә уңышка ирешергә мөмкин. Балаларга милли гореф-гадәтләр, милли традицияләр никадәр иртә бирелсә, шулкадәр яхшырак. Без педагоглар һәм ата-аналар халык мирасын бала тәрбияләүдә ныклы нигез, үтемле чара итеп куллана белсәк, белемле, тормышта үз урынын мөстәкыйль табарга

сәләтле, олыларга игътибарлы, хезмәт сөючән, намуслы, үз милләтен һәм башка халыкларны хөрмәт итүче шәхесләр үстерә алачакбыз.

**Программаның төп максаты:**

- һәр баланың иҗади потенциалын ачу;
- бала интеллектын формалаштыру;
- җәмгыятьнең аңлы, сәламәт әгъзаларын тәрбияләү;
- танып-белү процессын максатчан үстерү.

**Программаның төп бурычлары:**

**Дидактик:**

- татар теленә уку фәне буларак кызыксыну үстерү;
- татар теле грамматикасы буенча белем, күнекмәләр булдыру;
- укучыларның сүзлек запасларын үстерү;
- укучыларда татар теленә хөрмәт һәм ихтирам тәрбияләү, телнең чисталыгын, дөреслеген саклау, телне, халыкның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту;

**Тәрбияви:**

Китап белән эшли белү культурасы тәрбияләү;

.укучыларда фикерләү культурасы, кызыксыну формалаштыру һәм үстерү;

**Үстерелешле:**

- укучыларның фикер йөртүен һәм тапкырлыкларын үстерү;
- төрле сүзлекләр белән эшли белүләрен үстерү;

**<u>Укучыларның белем, күнекмәләренә төп таләпләр</u>**

**<u>Предметны укыту программасына нигезләнеп үзләштерү нәтиҗәләре</u>**

***Шәхескә юнәлтелгән УУГ (универсаль уку гамәлләре)***

- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану;
- түгәрәктә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану;
- үз фикереңне әйтә белү;
- иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру;

*Танып белү универсаль уку гамәлләре*

- үзенә кирәкле информацияне таба белү; анализлый һәм информацияне бәяли белү;
- логик фикерләү чылбырын төзү;
- тәкъдим ителгән план ярдәмендә предмет, күренешләрне сурәтләү;
- тәҗрибә куллану аша нәтиҗә чыгару;

**Регулятив (көйләгеч) универсаль уку гамәлләре**

- -белгәнне һәм белмәгәнне аера белү;
- -үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, рәсемнәр ярдәмендә биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- -эшләнәчәк эшкә мөстәкыйль максат куя белү;
- -үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;
- -бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру;
- түгәрәктә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау;
- -үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;. уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый һәм ул ситуациядән чыгу юлларын таба белү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

- тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү;
- күзаллау, фаразлау; логик фикер йөртү осталыгы; күршең белән
- хезмәттәшлек итү; фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру; үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау;
- җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү; иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү.

Тәрбия эшчәнлеген оештыру таләпләре:

- тәрбиянең сыйфатын булдыру;
- тәрбиянең эчтәлеге, форма, метод, бурыч һәм максатына туры килүе;

- укучыларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү өчен шартлар булдыру;
- шәхескә юнәлдерелгән юнәлешне тормышка ашыру;

**Календарь-тематик план**

| № | Үтәлү вакыты | Тема | Сәгать | Тибы | Предмет эшчәнлеге |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 03.09. | **Морфология.** Сүз төркемнәре турында төшенчә | 1 | Морфология фәне турында аңлату, сүзләрнең төркемнәргә бүленүен өйрәнү. | Сыйныфташ ларыңа карата ихтирамлы булу хисен тәрбияләү |
| 2 | 10.09. | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Сүзлек диктант | 1 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне тану күнекмәсен үстерү; күнегүләре, ялгызлык исемнәрне баш хәрефтән яза белү | Бер-береңә ярдәм итеп эшләргә өйрәнү |
| 3 | 17.09. | Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формалары, килеш белән төрләнеше | 1 | Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формаларын өйрәнү, күплек сан формасын ясаучы кушымчаларны куллана белү, килеш белән төрләндерергә өйрәнү, | Татар теленә ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләген үстерү |
| 4 | 24.09. | Исемнәрнең – тартым, тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | 1 | Предметның кайсы затка караганлыгын тартым кушымчалары ярдәмендә белдерелүен аңлау, исемнәрнең – тартым, тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнешен үзләштерү | Бер-береңә ихтирам, игътибарлылык, үз көчеңә ышану хисләрен тәрбияләү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | 01.10. | Исемнәрне кабатлау, морфологик анализ. Тест эшләү. | 1 | Аерым кагыйдәсе (тәртибе буенча) исемнәргә морфологик анализ ясау күнекмәләрен үзләштерү, олимпиадалар вакытында куллана белү | Дәрестә уңай атмосфера тудыру. Алга куйган максатыңа ирешә белү, үз көчеңә ышану хисләрен тәрбияләү |
| 6 | 08.10. | Контроль диктант | 1 | Язма эшне грамоталы итеп язу | Иптәшеңә ярдәм тәкъдим итү, хезмәттәшлек итә белү |
| 7 | 15.10. | Сыйфат турында төшенчә. Сыйфатларның ясалышы | 1 | Сыйфатның мәгънәсе, белдерелүе, сораулары турында мәгълүмат бирү; сыйфатланмышның нәрсә икәнен аңлату, сөйләмдә куллана белү, тексттан аерып ала белү, сыйфатларның ясалышын өйрәнү. | Дәрестә уңай мохит тудыру |
| 8 | 22.10. | Сыйфат дәрәҗәләре. Асыл һәм нисби сыйфатлар | 1 | Сыйфатның дүрт дәрәҗәсе турында мәгълүмат бирү, дөрес итеп кушымчалар ялгау, аларны дөрес итеп язарга өйрәнү, тексттан нинди дәрәҗәдә икәнлеген аерырга белү, сөйләмдә куллану. Асыл һәм нисби сыйфатларның мәгънәсен, белдерүләрен өйрәнү, аларны кайсы төргә керүләрен аерырга өйрәнү | Яңа уку материалына һәм аны үзләштерү юлларына кызыксыну белдерү |
| 9 | 05.11. | Сыйфатларны кабатлау, морфологик анализ. Тест эшләү | 1 | Дәреслектәге күнегүләрне эшләү, тестлар эшләп, үз-үзеңне тикшерә алу. Сыйфатларга морфологик анализ ясарга өйрәнү; бирелгән тәртип буенча морфологик анализ ясау күнекмәләрен камилләштерү | яңа уку материалына һәм аны үзләштерү юлларына кызыксыну белдерү; |
| 10 | 12.11. | Сан турында төшенчә. Саннарның исемләшүе | 1 | Санның мәгънәсе, сораулары, белдерелүен өйрәнү, саналмыш турында мәгълүмат алу, саннарны сөйләмдә дөрес итеп куллана белү, дөрес язарга | Төркемдәшләреңә хөрмәт хисе белән карарга өйрәнү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | өйрәнү; саналмышсыз килгәндә исемләшүен мисаллар өстендә аңлата белү,тикшерү | |
| 11 | 19.11. | Сан төркемчәләре. Микъдар саны. Сүзлек диктант | 1 | Сан төркемчәләренең биш төргә бүленүе, микъдар санының мәгънәсе,белдерелүе, сорауларын өйрәнү, аның рус теленә охшаш булуын аңлату, телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү, дөрес язарга белү | Үз уңышларың, уңышсызлыкларың турында фикер йөртү |
| 12 | 26.11. | Тәртип саны, чама саны | 1 | Тәртип, чама саннарының мәгънәсе,белдерелүе, сорауларын өйрәнү, тексттан саналмышы белән табып әйтү,телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү, дөрес язарга белү | Саннарны тирәнрәк өйрәнү теләген булдыру |
| 13 | 03.12. | Бүлем саны, җыю саны | 1 | Бүлем, җыю саннарының мәгънәсе,белдерелүе, сорауларын өйрәнү, тексттан саналмышы белән табып әйтү,телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү, дөрес язарга белү, төрле саннардан төзелгән парлы саннарның да чама саны булуын аңлату | Саннарны тормышта, телдә дөрес куллану теләген булдыру |
| 14 | 10.12. | Контроль изложение “Джек” (284 нче бит) | 1 | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү; ишеткәнне эзлекле, грамоталы, логик яктан дөрес итеп яза белү, яза белү күнекмәсен үстерү | Тел, сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү теләге булдыру |
| 15 | 17.12. | Саннарны кабатлау, морфологик анализ ясау. Тест эшләү. | 1 | Сан бүлеге буенча үткәннәрне кабатлау. Күнегүләр һәм тестлар эшләү Саннарга морфологик анализ ясарга өйрәнү күнекмәләрен камилләштерү | Укуга уңай мотив тудыру, үзлектән белем алуга омтылыш. |
| 16 | 24.12. | Рәвеш турында төшенчә. | 1 | Рәвешнең мәгънәсе, белдерелүе, сораулары, кайсы сүзне ачыклавын | Яңа теманы үткәндә, телне үзләштергәндә, яңалыкларны күрә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Рәвешләрнең ясалышы. | | өйрәтү, телдән һәм язма сөйләмдә куллану, тексттан рәвешләрне дөрес итеп табарга өйрәнү .Рәвешләрнең ясалышын өйрәнү. | белү теләге уяту |
| 17 | 14.01. | Рәвешләрнең мәгънә төркемчәләре. Саф рәвешләр | 1 | Хаталар өстендә эшләү; Рәвешләрнең мәгънә төркемчәләрен өйрәнү; Саф рәвешләрнең мәгънәсе, белдерелүе, язылышы, сөйләмдә кулланылуын өйрәнү | Укучыда телне өйрәнү кирәклеген аңлау күнекмәләре булдыру |
| 18 | 21.01. | Охшату-чагыштыру, күләм-чама рәвешләре | 1 | Охшату-чагыштыру, күләм-чама рәвешләренең мәгънәсе, белдерелүе, язылышы, сөйләмдә кулланылуын өйрәнү | Белем алуга омтылыш булдыру |
| 19 | 28.01. | Урын, вакыт рәвешләре | 1 | Вакыт, урын рәвешләренең мәгънәсе, белдерелүе, язылышы, сөйләмдә кулланылуын өйрәнү | Белем алуга омтылыш булдыру |
| 20 | 04.02. | Сәбәп – максат рәвешләре | 1 | Сәбәп-максат рәвешләренең мәгънәсе, белдерелүе, язылышы, сөйләмдә кулланылуын өйрәнү | Укуга булган уңай мөнәсәбәтне күрсәтә алу |
| 21 | 11.02. | Рәвешләрне кабатлау, морфологик анализ ясау. Тест эшләү | 1 | Рәвеш бүлеге буенча үткәннәрне кабатлау. Күнегүләр һәм тестлар эшләү Рәвешләргә морфологик анализ ясау күнекмәләрен ныгыту | Уку процессында кызыксындыру булдыру |
| 22 | 18.02. | Контроль диктант “И минем торган җирем!” (282нче бит) | 1 | Язма эшне грамоталы итеп язу | Дәрестә уңай халәт тудыру |
| 23 | 25.02. | Алмашлык турында төшенчә, | 1 | Алмашлык турында төшенчә бирү. Сөйләмдә һәм язма сөйләмдә куллана | Укуга уңай мотивация булдыру. Белем һәм күнекмәләрне |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | төркемчәләре, ясалышы | | белү. Алмашлыкларның төркемчәләрен, ясалышын өйрәнү; | өйрәнүгә, уңышларга ирешүгә шатлану хисе булдыру |
| 24 | 04.03. | Зат, тартым алмашлыклары | 1 | Зат, тартым алмашлыкларының мәгънәсе, белдерелүе, килеш белән төрләнүләре, берлек һәм күплек санда килүләрен өйрәтү, тексттан аера, килеш белән төрләндерергә, җөмләләр төзеп язарга өйрәнү | уку эшчәнлегендә үзбәя куя белү; |
| 25 | 11.03. | Күрсәтү, сорау алмашлыклары | 1 | Күрсәтү, сорау алмашлыкларының мәгънәсе, белдерелүе, килеш белән төрләнүләре, тартым кушымчасы алулары, берлек һәм күплек санда килүләрен өйрәтү, тексттан аера, килеш белән төрләндерергә, җөмләләр төзеп язарга өйрәнү | Укуга уңай мотивация булдыру |
| 26 | 18.03. | Контроль изложение “Җирән кашка” (285 нче бит) | 1 | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү; ишеткәнне эзлекле, грамоталы, логик яктан дөрес итеп яза белү, яза белү күнекмәсен үстерү | Тел, сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү теләге булдыру |
| 27 | 01.04. | Билгеләү, билгесезлек алмашлыклары | 1 | Билгеләү, билгесезлек алмашлыкларының мәгънәсе, белдерелүе, килеш белән төрләнүләре, тартым кушымчасы алулары, берлек һәм күплек санда килүләрен өйрәтү, тексттан аера, килеш белән төрләндерергә, җөмләләр төзеп язарга өйрәнү | Телнең матурлыгын тоемлый белү, укуга кызыксыну булдыру; |
| 28 | 08.04. | Юклык алмашлыклары. Алмашлыкларга морфологик анализ | 1 | Юклык алмашлыкларының мәгънәсе, белдерелүе, сорау алмашлыкларына һич, бер сүзләре ялганып ясалулары; аларны дөрес язу күнегүләре,тексттан аера, | Укуда уңышларга ирешү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | ясау. | | җөмләләр төзеп язарга өйрәнү<br>Алмашлыкларга морфологик анализ ясау күнекмәләрен ныгыту | |
| 29 | 15.04. | Контроль диктант | 1 | Язма эшне грамоталы итеп язу | Дәрестә уңай халәт тудыру |
| 30 | 22.04. | Фигыль төркемчәләре. Затланышлы фигыльләр. Боерык фигыль. Аңлатмалы сүзлек диктанты ”Алтының белән мактанма”<br>(58 нче бит) | 1 | Башлангыч формадан боерык фигыль формасын ясап, сөйләмдә урынлы куллана белү. Боерык фигыльне зат-сан белән төрләндереп, бу сүз төркеменең 1 нче затта кулланылмау үзенчәлеген табу, басымны дөрес итеп куярга өйрәнү. | Уку эшчәнлегендә үзбәя куя белү; |
| 31 | 29.04. | Хикәя фигыльнең заман белән төрләнүе. Хәзерге заман хикәя фигыль. Тест эшләү | 1 | Хәзерге заман хикәя фигыль формасын ясап, аны сөйләмдә урынлы куллана белү.<br>Билгеле һәм билгесез үткән заман, киләчәк заман хикәя фигыльне аера белү, бу ике төрне сөйләмдә урынлы | Яңа уку материалына һәм аны үзләштерү юлларына кызыксыну белдерү; |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | куллана белү. | |
| 32 | 06.05. | Үткән заман, киләчәк заман хикәя фигыль. Искәртмәле диктант “Гармун моңы буйлап” (55нче бит) | 1 | Билгеле һәм билгесез үткән заманның ике төрен дә сөйләмдә урынлы куллана белү. Билгеле һәм билгесез киләчәк заманның ике төрен дә сөйләмдә урынлы куллана белү. | Туган телне ярату хисен тәрбияләү |
| 33 | 13.05. | Шарт фигыль. Иҗади диктант “Надан кеше” (60нчы бит) | 1 | Шарт фигыльне сөйләмдә урынлы куллана белү, иярченле кушма җөмлә төзи белү. Фигыльләрне шарт фигыль формасында зат-сан белән төрләндерергә өйрәнү. | Яңа уку материалына һәм аны үзләштерү юлларына кызыксыну белдерү; |
| 34 | 20.05. | Уку елын йомгаклауга контроль тест эшләү.Уку елына йомгак. | 1 | Барлык өйрәнгәннәрне дөрес итеп куллана белү | Алган белемнәрне тикшерү |

Уку предметын үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр

***“Морфология”*** бүлегендә укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:
-татар телендәге сүз төркемнәрен аера белә;
-аерым сүз төркеменә керүе ягыннан (морфологик яктан) сүзләрне тикшерә;
-сүз төркемнәренең төрле формаларын хәзерге татар әдәби теле нормалары кысаларында куллана;
-морфологик белем һәм күнекмәләрне сүзләрнең дөрес язылышына, башка төрле анализларга бәйле рәвештә куллана.